| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>**СОВЕТ ЧИСТОПОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>**ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ** |
|---|---|---|

***Решение*** ***Карар***

**2021елның 03 феврале** **г.Чистополь** **№ 5/2**

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең муниципаль милкендәге күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләрен арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектерү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2020 елның 13 маендагы 55/7 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 01 апрелендәге 98-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Татарстан Республикасы дәүләт милкендә булган күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектерү шартларына һәм срокларына таләпләр билгеләү турында» 2020 елның 03 апрелендәге 439 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт милкендәге күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектерү шартлары турында» 2020 елның 22 апрелендәге 314 номерлы карарының 2 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең муниципаль милкендәге күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектереп тору шартлары, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләрен арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектерү шартлары турында» 2020 елның 13 маендагы 55/7

номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы муниципаль милкендәге күчемсез милекне арендалау шартнамәләре буенча, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләрен арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектереп тору шартлары турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Арендатор икътисадый эшчәнлекнең төп яисә өстәмә төрләре буенча билгеләнә, аның турында мәгълүмат юридик затларның Бердәм дәүләт реестрында йә индивидуаль эшкуарларның Бердәм дәүләт реестрында 2020 елның 1 апреленә торышы буенча бирелә.»;
3 пунктта:
беренче абзацта «2020 елның 1 октябренә кадәр» сүзләрен «2021 елның 1 гыйнварына кадәр» сүзләренә алмаштырырга;
«б» пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«б) кичектерү тиешле чор өчен аренда түләве күләмендә бирелә;».

2. Әлеге карарны «Чистай хәбәрләре» газетасында яисә Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында www.chistopol.tatarstan.ru урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе һәм депутат эшчәнлеге мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Чистай муниципаль
районы башлыгы Д.А. Иванов